Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Сарсазы авылы җирлегенең Уракчы авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлеге составына керүче Уракчы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

# КАРАР

2019 елның 10 ноябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 9 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең Уракчы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Вак таш сатып алу һәм китертү, Уракчы авыл эчендәге юлларга вак таш җәю, кар чистарту, бульдозер эшләре.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 125 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 81 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 81 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең Уракчы авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең Уракчы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Вак таш сатып алу һәм китертү, Уракчы авыл эчендәге юлларга вак таш җәю, кар чистарту, бульдозер эшләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең Уракчы авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең Уракчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Вак таш сатып алу һәм китертү, Уракчы авыл эчендәге юлларга вак таш җәю, кар чистарту, бульдозер эшләре.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Сарсазы авыл җирлеге башлыгы ________________ С.С.Мусин